**СОВЕТ КРАСНООКТЯБРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
423193, РТ, Новошешминский район, поселок совхоза «Красный Октябрь», улица Школьная, 3

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЫЗЫЛ ОКТЯБРЬ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
423193, РТ Яңа Чишмә районы ,Кызыл Октябрь с-зы поселогы , Мәктәп урамы, 3

тел.:(884348)33-2-28, факс: (8-84348)33-2-09, Kokt.Nsm@tatar.ru

КАРАР КАРАР

2020 елның «30» октябреннән № 1

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Красный Октябрь авыл җирлегенең Красный Октябрь с-зы поселогы гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Красный Октябрь авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22, 81 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Красный Октябрь җирлеге башлыгы

Карар кабул итте:

1. 2020 елның 16 ноябрენә сәгать 15.00 дә Спортивная,28 адресы буенча урнашкан Красный Октябрь авыл мәдәният йортында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Красный Октябрь совхозы поселогының Спортивная урамындагы 1-32 йортларда, Совет урамы 1-20 йортларда яшәүчеләр белән Красный Октябрь авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2020 елның 16 ноябренә сәгать 16. 30 да Спортивная,28 адресы буенча урнашкан Красный Октябрь авыл мәдәният йортында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Красный Октябрь совхозы поселогының Мәктәп урамы 1-21, Үзәк урам 1-21,Комсомол урамы 2-12 йортларда яшәүчеләр белән Красный Октябрь авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2020 елның 19 ноябренә сәгать 15. 00 да Луговая урамындагы 4 йорт янында Яңа Чишмә муниципаль районы Красный Октябрь совхозы поселогының Луговая урамы 1-18, Заливная урамы 4-6 йортларда яшәүчеләр белән Красный Октябрь авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. 2020 елның 19 ноябренә сәгать 16. 00 да Мәктәп урамындагы 3 йортта урнашкан Красный Октябрь авыл җирлегендә Башкарма комитеты бинасында Красный Октябрь совхозы поселогының Мәктәп урамы 21-40, Яшьләр урамы 1-31 йортларда яшәүчеләр белән Красный Октябрь авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын билгеләргә
5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Красный Октябрь халкы исемлеген сайлау тәртибе территориаль билге буенча башкарылырга тиеш.

6. Гражданнар җыенының этапларын оештыру һәм уткәрү Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Красный Октябрь авыл җирлеге Башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

7. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

««2021 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Красный Октябрь авыл җирлегенең Красный Октябрь совхозы поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, БВСда катнашучылар, БВСда һәм һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучының тол хатыннары, балачактан инвалидлар, 1 төркем инвалидлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә алынган акчаларны Красный Октябрь совхозы поселогы территориясендә түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эш өчен түләү);

- җәйге чорда территориядәне чүп үләннәреннән чистарту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- -юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (смета буенча юл төзелеше: вак таш сатып алу, нигез әзерләү, ташу, җәю, эшләр өчен түләү), Яшьләр урамы, Совет урамы буенча.

«РИЗА» «КАРШЫ»

9. Әлеге карарны гражданнар җыены уздырыла торган көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, «Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә), Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Красный Октябрь авыл җирлегенең Красный Октябрь авылының мәгълүмат стендларында урнаштырырырга.

10. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Красный Октябрь авыл җирлеге Башлыгы В.В. Захаров